КӘСЕПЛЕ АВЫЛ

Яморзада табигать биргән нигъмәтнең файдасын күрә беләләр

> 2

УКУЧЫ СҮЗЕ

«ВТ» укучылары хатларында – тормыш кыйпылчыклары

> 3

МАРАТ КӘБИРОВ:

«Кайвакыт үземне разведчик итеп тоям...»

> 4

ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Заказ биреп пешертү: замана шаукымымы, ялкаулыкмы?

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 106 (28879) | Сишәмбе | 26 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА



Илдар Мөхәммәтҗанов

ИРЕКТӘМЕ, ЧИТЛЕКТӘМЕ?

БУЛАЧАК СТУДЕНТЛАРГА КАЙДА ЯШӘҮ КУЛАЙРАК?

Имтихан, укырга керү мәшәкатьләре белән сыналган кичәге мәктәп балаларының бүген баш өстенә түбә эзләп йөргән көннәре. Берне бишкә бүлеп яшәргә өйрәтә торган тулай торакка урнашасымы, мөстәкыйльлек эзләп, фатирга керәсеме? Кайсы очракта кесәгә дә, кешегә дә отышлырак? Шуны ачыкларга тырыштык.

Шартларына күрә бәясе

Казан – туристлар өчен генә түгел, студентлар арасында да популяр шәһәр. Башкаланың уку йортларында 168 меңләп кеше белем ала. Калага укырга дип, якынтирәдән генә түгел, чит төбәк һәм илләрдән дә киләләр. Бу кадәр кеше каядыр урнашырга тиеш бит инде. Билгеле, тулай торак барысын да сыендырып бетермәячәк. Өлешсез калганнарга фатир эзлисе.

Игъланнар сайтына кереп, без дә Казан районнарында бер бүлмәле фатир бәяләренә күз салдык. Шунысын искәртик: торак хакы бер айга исәпләнгән, коммуналь хезмәтләр бу суммага кермәгән. Димәк, бу суммага, уртача алганда, тагын 4–5 мең сум өстисе әле.

Районына карата фатирның бәясе дә үзгә. Әйтик, Авиатөзелеш районында 8 мең сумга да бүлмә табарга мөмкин. Торак хакларының уртачасы биредә 12–13 мең сум тирәсе.

Вахит районында фатирлар кыйммәтрәк йөри. Аңлашыла да, үзәк бит. Уртача 17 мең сумга бүлмә табарга мөмкин.

Киров районын шартлары һәм бәяләре буенча иң кулай районнарның берсе дип санарга мөмкин. Торак хакы биредә 13 мең сумнан башлана.

Мәскәү районында – 16, Яңа Савин районы – 17–20, Идел буе районында бер бүлмәле фатирда яшәп тору бәяләре аена 17 мең сумнан башлана. Совет районында да шартлары канәгатьләндерерлек фатирларны шул бәядән табарга була.

Тулай торак бәяләренә килгәндә, аларны республиканың берничә вузы мисалында чагыштырып карарга булдык.

Мәгълүм булганча, Казан федераль университетының башкалада берничә тулай торагы бар. Һәркайсында тору шартлары да, түләве дә төрле. Бюджетта укучыларга тулай торакта урын өчен 670 сумнан 700 сумга кадәр түлисе булса, коммерция шартларында укучылар өчен яшәү хакы – 1100–1250 сум чамасы.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының булачак студентлары өчен тулай торакта яшәү бәясе 500–1200 сумга төшәчәк. Бәя әлеге дә баягы студентның нинди шартларда укуына бәйле.

Казан дәүләт илкүләм тикшеренү техник университеты (КНИТУ-КАИ) тулай торакларында бер айга яшәү хакы шулай ук төрлечә: 516 сумнан башлап 591 сумга кадәр.

Чиләгенә күрә капкачы

Торак хакы акча янчыгының калынлыгы белән һәрвакыт тәңгәл киләме икән? Яшәр өчен башкаланың кайсы районына күбрәк өстенлек бирәләр? Кызыксындырган сорауларга «Лефарт» милек агентлыгы җитәкчесе Ләйсән Гыйләҗиева ачыклык кертте.

– Булачак студентларга төп киңәш шул: фатир эзләүне алданрак башласыннар иде. Август ахырында алар шулкадәр күбәя ки, хәтта тәкъдимнәр дә азаеп китә. Шул рәвешле бәяләр дә күтәрелә башлый, – ди белгеч. – Фатирны арендага биреп торучылар да вазгыятьне аңлый бит. Күп кенә яшьләр игъланнар сайтларындагы тәкъдимнәрне барлап куя да, август аенда барып карарбыз, дип өметләнеп тора. Әмма аларның күбесе арендага бирелгән була, кайсыларының шартлары, мәгълүматлары тәкъдим ителгәнчә булмый. Сөйләшеп, шалтыратып, кешесен күреп хәл итәргә кирәк, рекламага гына ышанырга ярамый. Бик арзан бәягә кызыгып, бик иске йортларны карамасыннар иде. Анда торган баланың ата-анасына борчу-мәшәкате күп була. Гадәттә, андый торакларда тормышы бик үк имин булмаган кешеләр торырга мөмкин. Наркоман, хәмер белән дус кешеләр, әйтик. Яңа гына шәһәргә килгән балага куркыныч бу.

Белгеч сүзләренчә, яшь буынның өмет иткәннәре чынбарлык белән туры килми. «Хәзерге көндә яхшы дип саналган фатирда торасың килсә, аена 20–25 мең сум түләргә кирәк. Вазгыять шундый. Билгеле, күп нәрсә торакның нинди комплекста, нинди урында урнашуына да бәйле. Ләкин 20 мең сум – уртача бәя. Күп очракта яшьләр бер бәягә генә карый. Ягъни 20 мең дип язылган икән, шуны түлим дә бетте дип саный. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү дә бу суммага кермәскә мөмкин бит әле. Әйтик, фатирны риэлтор белән эзлисең икән, аның комиссиясе була, күп кенә фатир бирүчеләр залог сорый. Милекчеләр белән бу хакта да сөйләшергә кирәк», – дип аңлатты Ләйсән Гыйләҗиева.

Ахыры 2 нче биттә >

Чыгымны да күрсәтергә

Россия Хезмәт министрлыгы түрәләр, шулай ук бюджет оешмалары һәм дәүләт корпорацияләре җитәкчеләренең «аппетиты»н кысмакчы. Министрлык Россия законына җитәкчеләрнең чыгымнарына контрольне көчәйтүне күздә тоткан төзәтмәләр керткән. Оешмалар башлыклары, шул исәптән мәктәп директорлары, хастаханә-сырхауханәләрнең баш табиблары, балалар бакчалары мөдирләрен керемнәре һәм чыгымнары турында хисап тотарга мәҗбүр итмәкчеләр. Әлегә алар, закон нигезендә, керемнәрен генә күрсәтергә тиеш.

Коррупциягә каршы чара барлыгы 206,6 мең кешегә кагылыр дип уйланыла. Росстат мәгълүматлары буенча, илдә дәүләт һәм муниципаль оешмалар шул санда. Закон проекты хупланган да инде. Гамәлдәге закон буенча, җитәкчеләрнең чыгымнарына ел дәвамында автомобиль, күчемсез милек, кыйммәтле кәгазьләр, цифрлы валюта кебек кыйммәтле әйберләр белән алыш-бирешләр керә.

Бурычлыга юл ябык

Татарстан суд приставлары беренче яртыеллыкта бурычлы кешеләргә Россиядән чыгуны чикләү турында барысы 178 мең карар (бурычның гомуми суммасы – 48 миллиард сум) булдырган. Бу – алимент, салым, кредит бурычын һ.б. түләтү турында карарлар.

Исегезгә төшерәбез: суд приставлары әҗәтен түләүне сузып йөрүчеләргә чит илгә чыгуны тыярга мөмкин. Шуңа күрә ял итү өчен кая да булса барырга җыенганчы, иң элек бурычлымы-түгелме икәнлегеңне барларга кирәк. Закон нигезендә, бурыч 30 мең сумнан арткан очракта чит илгә чыгуга киртә куела. Шунысы да бар: бурычны ике айдан күбрәк вакыт түләмәү очрагында, әҗәт күләме инде 10 мең сум булганда да суд приставы шушы карарны чыгара. Шулай ук чит илдә ял итәргә ниятләүчеләр өчен алимент түләүгә, сәламәтлеккә, матди һәм (яки) мораль зыян китерүне каплауга бәйле бурычлары күләме дә ун меңнән артмаска тиеш.

Әҗәтен түләмәүчеләргә Татарстан эчендә шәхси автотранспортта сәфәрләр планлаштыру да киңәш ителми. Ник дигәндә, суд приставлары, Дәүләт автомобиль инспекциясе хезмәткәрләре белән берлектә, юлларда рейдлар үткәреп килә. Бурыч 3 мең сумнан артып китсә, машина, арест салынып, махсус стоянкага җибәрелергә мөмкин.

«Татар-информ»

Яшәеш

Сызмыйча тор шырпыңны

Быел республикада урман янгыннары теркәлмәгән. Алай да тынычланырга ярамый. Көннәрнең эссе торуы аркасында, хәзерге вакытта Татарстанда өченче дәрәҗә янгын куркынычы саклана. Урманчылар тәүлек буе кизү тора.

Исегезгә төшереп китәбез: Татарстанда, янгын куркынычы зур булу сәбәпле, 8 июльдән урманнарга керү тыелды. Чикләү тиздән тәмамланачак. Әмма бу әле урманнарга кереп, учак ягып, күңел ачарга рөхсәт дигән сүз түгел. Татарстан урманчылары, һава торышына карап, чикләүләрне озайтырга да мөмкин. Хәтерләсәгез, узган ел андый сезон 25 октябрьгә кадәр дәвам иткән иде.

– Быел урманнарда бер янгын да теркәлмәде. Әмма үләнгә ут кабу очраклары бар. Җәй башыннан бүгенгә кадәр республика халкыннан 349 шундый хәбәр килгән. Хәзерге вакытта Лаеш районында урнашкан Урман янгыннарын сүндерү үзәге хезмәткәрләре халык белән тыгыз элемтәдә. Һәрдаим очрашулар үткәрәләр, аларга ут куркынычы турында аңлаталар. Урманнарны һавадан да, космостан да, җәяү дә күзәтәләр, – ди Урман хуҗалыгы министрлыгының матбугат бүлеге җитәкчесе Альмира Нуретдинова.

Татарстанда янгынга әзерлек көчле. Урманчылар иртә яздан көзгә кадәр ут чыкмасын өчен барысын да эшли. Төрле типтагы 25 урман-янгын станциясе эшли. 14 урында янгынга каршы җиһазлар әзерләп куелган. Урманнарны 1 меңгә якын кеше саклый. Казандагы шәһәр яны урманчылыгы җитәкчесе Илнур Кәшәфиев фикеренчә, кешеләр игътибарлы булса, янгыннар бөтенләй булмас иде.

– Барыбыз да беләбез: ут чыгуга күп очракта кеше гаепле. Гел кисәтү, аңлату кирәк. Бергәләп саклаганда, урманнарга зыян килмәс иде, – ди ул. – Ял итүчеләрне дә аңлап була. Җәй көне табигать кочагында ял итәселәре дә киләдер. Тик таләпләр бөтен кешегә бер: әлегә урманнарга һәм аның янәшәсендәге тугайларга керми торырга кирәк. Бигрәк тә учак ягарга, коры үләнгә ут төртергә ярамый. Шырпыны сызмый торырга кирәк, кыскасы.

Урманчылар халыкны да уяу булырга чакыра. Берәр урында үлән янганын күргән очракта, 8-800-100-94-00 телефонына хәбәр бирүләрен үтенәләр.

Быелдан янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозган өчен штраф күләме дә үзгәрде. Исегезгә төшерәбез: элек гади кешеләр өчен штраф күләме 1500 сум булса, хәзер бу сумма, ун тапкыр артып, 15–30 меңгә кадәр җитте. Вазыйфаи затлар өчен 30 меңнән 50 мең сумга кадәр штраф каралган (элек 10000–20000 сум иде). Юридик затларга штраф күләме – 100 мең сумнан 400 мең сумга кадәр. Урман-парк зонасы янында чүп-чар яки коры-сары яндыручыларга 30 мең яки 40 мең сум штраф түләргә туры киләчәк. Вазыйфаи затлар өчен штраф күләме – 40 мең сумнан 60 мең сумга кадәр, юридик затларга 300 мең сумнан 500 мең сумга кадәр тәшкил итә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Илсур МЕТШИН, Казан мэры:

Россиядә узмый калган халыкара спорт ярышлары саны буенча иң зур зыянны Казан күрде. Кызганыч, спорт сәяси басым коралына әйләнде. Ләкин мин моның вакытлы күренеш булуына ышанам. Спорт турнирын уздырмый калырга мөмкин, ләкин кешеләрне сәламәт яшәү рәвеше алып барудан, профессиональ спорт белән шөгыльләнүдән тыярга ярамый.

(Казан Башкарма комитетының атналык киңәшмәсендә әйткәннәрдән)

ТАТАРСТАНДА – ЙОМЫРКА ҖИТЕШТЕРҮ

Быелның гыйнвар – май айларында республикада 491,1 млн данә йомырка җитештерелгән. Бу – Россия буенча сигезенче, Идел буе федераль округында өченче күрсәткеч.



Чирләүчеләр арткан

Узган атнада Россиядә коронавирус инфекциясен йоктыручылар саны яртылаш диярлек – 48,9 процентка арткан. Шуңа да карамастан, хастаханәгә озатылучылар 5,3 процентка кимегән. ТАСС хәбәренә караганда, 70 төбәктә – чирләүчеләр саны, 29ында хастаханәгә салынучылар саны арткан. Узган тәүлектә илдә 6571 кешенең инфекция йоктыруы ачыкланган. Бер көн алдан бу сан 7523 тәшкил иткән. 34 кеше вафат булган, 4234е савыккан.

Соңгы тәүлектә республикада коронавирус йоктыруның 42 яңа очрагы теркәлгән. 19 сырхау хастаханәгә озатылган. Шул рәвешле пандемия башланганнан бирле республикада вирус йоктыручылар саны 153578гә җиткән. Барлыгы 150279 кеше, тернәкләнеп, аягына баскан, шул исәптән 52се – соңгы көндә. Яңа үлем-китем очраклары теркәлмәгән. Бу шомлы күрсәткеч элеккечә үк – 1996.

Яңгырлы эссе һава

Бу атнада Татарстанда яшенле көчле яңгырлар, урыны белән боз яву көтелә. Шул ук вакытта көндез һава температурасы +31 градуска җитәчәк. Синоптиклар чәршәмбе – 27 июльгә республикада кыска вакытлы яшенле яңгырлар фаразлый. Пәнҗешәмбе һәм җомгада – 28, 29 июльдә көчле яңгырлар көтелми. Көндез һава температурасы +25...+31 градус, төнлә +14...+20 градус булачак. Гидрометеоүзәкнең башлангыч мәгълүматларына караганда, ял көннәрендә – янә яшенле яңгырлар. Әмма бераз җиләсләнә. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +22...+27 градус чикләрендә генә тирбәләчәк.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙ ЗУР СУГЫШКА ТАБА АТЛЫЙ

Дөньякүләм киеренкелек үткән атнада дөньяның барлык почмакларында да кискен көчәйде. Италия премьер-министры Марио Драги, ниһаять, икенче омтылышта отставкага китте. Аның беренче отставкасын Президент кабул итмәгән иде. Әмма илдә социаль киеренкелек көчле. Парламенттагы идарәче коалиция, бүлгәләнеп, премьер-министрга арттан пычак кадады. Төрле партияләрнең аркадашлыгы нәтиҗәсендә генә премьер кәнәфиендә утыра алган Драги, аркадашлык тукталу белән, постын ташларга мәҗбүр булды. Европаның башка дәүләтләрендә дә хәл киеренке. Француз протесты яңадан урамда учаклар яга. Нидерланд фермерларының протест хәрәкәте башка илләргә дә җәелә. Латин Америкасындагы Панамада ярсыган халык, югары бәяләргә һәм коррупциягә каршы көрәшәбез дип, шулай ук урамнарга ут салды, ил ялкын эчендә.

Гыйракта да хәл катлауланды. Төрек чигеннән 8 генә километр ераклыктагы Парак шәһәрен төш вакытында көрд террорчылары утка тоттылар. Бу – туристлар күп җыела торган төбәк, 11 кеше үлде, егермеләп яраланды. Социаль челтәрләрдә Төркиянең һөҗүм итүе турында хәбәрләр таратылды. Бу уңайдан гыйраклылар зур гыйсъянчылык дәрте белән урамнарга чыктылар. Багдадтагы төрек илчелегеннән флаг салдырып алынды һәм яндырылды.

Зур бәхетсезлеккә, планета масштабында сугыш китереп чыгарырга ихтимал булган хәлләр исә Кытайда бөреләнә башлады. Кытайда зур дефолт булу һәм аның дөньякүләм кризисның башлангычына әверелү ихтималы хакында без «Ватаным Татарстан»да үткән көздә үк әйткән идек. Түләп бетерә алмаслык әҗәтләр кочагында калган чин иле банк кризисына таба зур бер адым ясады. Компартиянең, акча басып, ил икътисадын коткарырга азаплануы бөек кризис булып аваз бирергә җыена. Девелоперлар дефолты нәтиҗәсендә чин төзелеш тармагы икътисадны үзара түләмәүләр кризисына өстерәп кертте. Банклар төзүчеләргә кредит бирми башлады, төзелеш тукталу сәбәпле, ипотека кредиты алучылар шулай ук ипотека өчен түләүләрне туктаттылар. Кытай икътисадында әҗәтләр АКШныкына һәм Европаныкына караганда да зуррак. Триллионлаган доллар күләмендә акча басып, икътисадны яшәтергә тырышу кризисны бераз арткарак чигендерде, әмма тагын да масштаблырак финанс кризисы куркынычын арттырды. Хэнань провинциясендә банклар депозитлар буенча түләүдән баш тартты, чөнки акчалары юк. Кертем ияләре, ярсып, урамнарга чыкты. Урамнарда аларны танклар һәм башка калканлы техника каршы алды. Шаньдун провинциясендә дә шундый ук хәл. Процент капиталына корылган икътисад Кытайда бөек халык күтәрелеше вәгъдә итә башлады. Мондый чакта хакимиятләр кулында бер генә уен картасы бар. Пекин җиң эченнән шул картаны чыгарырга җыена. Global Times газетасы (Кытай компартиясе чыгара торган көндәлек рәсми газета) «Байденның Тайваньга бәйле карары нәтиҗәсендә Кытай һәм АКШ зур сугыштан бер генә адымда», – дип язды. Конгрессның вәкилләр палатасы спикеры Нэнси Пелоси Тайваньга визит ясарга җыена. Шул уңайдан чиннар хәрби һәм стратегик җавап бирергә вәгъдә итәләр. АКШ икътисадында да хәлләр ташка үлчим генә. Шулай булгач, ике якның да халыклар игътибарын зур сугышка юнәлдереп, барлык бәлаләрне шул китереп чыгарды дип котылырга омтылу теләге бик зур.

Россиядә

СТАВКА ТҮБӘНӘЯ, БӘЯЛӘР КҮТӘРЕЛӘМЕ?

Россиянең икътисади проблемалары Көнбатыштагыдан да, Кытайдагыдан да аерыла. Әйе, без дә глобаль процент капиталының басымы астында яшибез. Әмма чимал державасы буларак, энергетик кризис безне алай ук түбәнгә тартмый. Мартта акча янчыклары күтәрелә алмаслык булып югарыга киткән бәяләр халыкның сатып алу дәрәҗәсе түбән булу сәбәпле тотрыкланды, хәтта микроскоптан караганда гына күренерлек дәрәҗәдә булса да түбәнгә төшә башлады. Үткән атналарда финанс хакимиятләренең доллар курсын югарыга этүгә булган омтылышлары уңышсызлыкка очрады: валюталар тыңламый, һаман бәя югалта. Һиндстанда рупияне, мәсәлән, ничек тотып торырга белмиләр, курсы түбәнгә сикерә. Без, россиялеләр, билләрне кысып бусак та, немецлар кадәр үк сакчыллыкка әлегә өйрәнә алмадык. Германиянең 62 процент халкы тизрәк һәм сирәгрәк юына башлаган. Энергия чыганакларына бәяләр күтәрелү аларны шуңа этәрә.

Россиядә федераль хөкүмәт исә бәяләрнең төшүеннән һәм сумның ныгуыннан курка. Мәскәүдә торак базарында 2021 елның шул чоры белән чагыштырганда фатир тәкъдим итү 35 процентка арткан. Кешеләр кыйммәт бәядән артык фатирларын сатып калырга ашыгалар, әмма сорау артмый, киресенчә, кими. Икенчел торак базарында бәяләр черки томшыгы кадәр генә төште, диләр.

Сумның ныгуы россияле җитештерүчеләрнең мәнфәгатьләренә суга. Бульдозерлар, грейдерлар һәм төяү техникасы җитештерүчеләр зар елый: техниканы Кытайдан алу арзангарак чыга, безнекен алмыйлар, диләр. Чит илнең киң куллану товарлары басу куркынычы башка базарларга да яный, үзебезнекен җитештерү тукталу сәбәпле, эшсезлек арту куркынычы көчәя. Инновацион товарларны безгә бик бирмиләр, билгеле. Әмма аларны тиз генә җитештерүгә күчерү өмете юк дәрәҗәсендә. Илдә инновацион компанияләр саны 22 процентка кимегән.

Шундый шартларда Үзәк банк җитезрәк адымнар ясарга мәҗбүр булды. Җомга утырышында төп ставка кискен түбәнәйтелде: 9,5 процентттан 8гә калдырылды. Карар кабул ителгәннән соң үткәрелгән пресс-конференциядә Эльмира Нәбиуллина: «Бәяләрнең түбәнәюе туктаусыз диярлек инде менә 9 атна бара», – диде. Март күтәрелешеннән соң бәяләрне берничә тапкыр төшерсәләр дә чыдап булыр шикелле үзе, әмма хөкүмәттә алай уйламыйлар шул. Бәя түбәнәю зыянлы дип саныйлар. Ставка түбәнәйгәч, компанияләр һәм физик затлар, күбрәк кредит алып, икътисадны җанландырырлар, әчке тулай продуктның кискен кимүеннән котылырбыз дигән өмет белән яшиләр. Өметләрнең ни дәрәҗәдә тормышка ашарлык булуы бу атнада валюта курсларында ук күренер дип көтик. Доллар һәм евро югарыга китсә, Үзәк банк адымы уңышлы дип саналыр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ИРЕКТӘМЕ, ЧИТЛЕКТӘМЕ?

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Әңгәмәдәш сүзләренчә, мөрәҗәгать иткәндә студентлар фатирның кайда урнашуына игътибар бирә. «Үзәктә булсын, диләр. Күп кенә уку йортлары үзәктә бит. Ләкин мондагы торакларны карый башласаң, бәяләрнең югары булуы ачыклана. Аннан инде, аңлата башлагач, Идел буе, Мәскәү, Яңа Савин, Совет районнарына игътибар итәләр», – ди ул.

Горки, Җиңү проспекты, Имәнлек метро станцияләренә якын булган фатирларга сорау зур икән. Метросы булмаса да, Яңа Савин районы да популяр, чөнки бу тирәдә сәүдә үзәкләре, кафе, парк, кинотеатр, кыскасы, күңел ачу өчен урыннар байтак.

Тормыш мәктәбе

«ТНВ» каналы журналисты Инзилә Хөсәенованы тулай торак ветераны дип санарга мөмкиндер. Дүрт ел шунда яши. Студент чорының иң күңелле мизгелләре дә тулай торакка бәйле, ди.

– Беренче шәпкә бик ят, яшәп булмастай урын кебек тоелса да, соңыннан бу мохиткә ияләшәсең. Иң мөһиме – монда син бердәмлек һәм татулыкның нәрсә икәнен аңлыйсың. Әгәр төркемдәшләрең белән бер бүлмәгә туры килсәң, бигрәк тә. Кухняга чыгып, бергә күз ачып йомганчы ашарга әзерлисез, кичен, җыелышып, концерт куясыз. Ашарга пешергәндә тозың җитмәсә, гомумән, нинди генә проблема килеп чыкса да, күрше бүлмәдәгеләргә йөгереп керәсең. Тулак торакның бер тискәре ягы – суыткычта әле генә торган ризык бер мизгелдә юк булырга мөмкин. Тулай торакта чиста түгел, ничек яшәп була ул шакшыда, диючеләр бар. Минемчә, чисталыкны һәркем үзе булдыра. Бүлмәдәш кызларым белән торырга кергәндә, дүрт карават та шкаф кына бар иде. Юып-җыеп, тәрәзәләргә челтәрләр элеп, өстәлләргә җәймәләр җәйгәч, нәкъ үз өебез кебек булды. Тулай торакта яши-яши бер «пропуск» белән бер биш кешене үткәрү, сакчыларның күзенә чалынмый гына ишектән чыгып йөгерү буенча остага әйләнәсең. Кинотеатр, клублардан соңарып кайтканда, иртәнге сәгатьләргә кадәр кертмичә тотулары, вахтада утырып, синең ише соңга калганнар белән танышып-дуслашып бетүләр, тәрәзә кага-кага сакчы апаларның ачуын чыгарулар – онытылмас шуклыклар инде бу, – дип хатирәләргә бирелде ул. – Хәзер фатирда торам, шул еллар белән чагыштырам. Әйе, шартлар яхшырак, үз бүлмәңә үзең хуҗа, кереп чисталыкны да тикшереп йөрмиләр, душка да чират торасы юк. Шул чакта кичергән хисләр, маҗаралар җитми! Шуңа күрә һәркемгә шушы студент тормышының ким дигәндә бер генә аен булса да тулай торакта яшәп карарга киңәш итәр идем.

Җырчы Ризат Рамазановның да тулай тораклы тормышына бәйле истәлекләре байтак. Булачак хатыны Зиниранны да шунда очрата әле ул.

– Мин тулай торакта әйбәт егетләр белән тордым, дус булдык. Тулай торагыбызда уңайлыклар да начар түгел иде. Нәрсәсе читен: душыбыз бер генә булды. Дүшәмбе, чәршәмбе, җомга егетләр көне сала. Кухнясы аерым бер бүлмә булып җиһазландырылган, камералар да бар иде. Вахтерлар белән дә мөнәсәбәтләр яхшы булды. Илсөя Бәдретдинова төркемендә эшләдем бит, җырчы булгач, төнлә генә кайтылган чаклар булмады түгел. Мин тәрәзәгә шакып, 50 сум акча төртеп булса да тулай торакка керә идем. Зур тормышка аяк басу тулай торак бусагасыннан башлана. Егет кеше армиягә барырга мәҗбүр булган кебек, һәр студент та «общага» шулпасыннан «авыз итәргә» тиеш, – дигән фикердә ул.

Яңалык

Тыелган руль

Кагыйдә бозучылар машинасыз калырга мөмкин. 25 июльдән Россиянең Административ хокук бозулар кодексы (КоАП) һәм Җинаятьләр кодексындагы яңа үзгәрешләр гамәлгә керде. Йөртү хокукы булмаган килеш рульгә утырган кешегә моннан ары катырак җаваплылык яный.

КоАПның 12.7 маддәсенә яңа бүлек өстәделәр. Анда әйтелгәнчә, «права»сыз калган кеше рульгә утырган килеш икенче мәртәбә эләксә, аңа 50–100 мең сум күләмендә штраф салалар яки 150–200 сәгатьлек мәҗбүри эшкә хөкем итәләр. Элек исә ничә тапкыр эләгүенә карамастан, җәза бертөрле иде: 30 мең сум күләмендә штраф, 15 тәүлеккә кадәр административ кулга алу яки 100–200 сәгатьлек мәҗбүри эш.

Болардан тыш, «права»сыз йөрүчеләргә җинаять җаваплылыгы да яный. Җинаятьләр кодексына 264.3 маддәсе кертелде. Транспорт белән идарә итү хокукы алынып, моның өчен административ җәзага тартылган йөртүчеләрнең кабат рульгә утыруы ачыкланса, 150–200 мең сум күләмендә штраф салачаклар, 360 сәгатькә мәҗбүри эшкә хөкем итәчәкләр. Әле бер елга иректән мәхрүм ителү куркынычы да бар. Суд нинди генә карар чыгарса да, йөртүче хөкем ителгән кеше булып саналачак.

Берничә мәртәбә рульдә исерек килеш эләккән кешегә исә, гомумән, машинасыз калу куркынычы яный. Андыйлар өчен конфискация җәзасы каралган. Дөрес, ул утырган машина үзенеке булган очракта гына. Белгечләр мондый җәзаның ни дәрәҗәдә дөрес һәм гадел булуына карата шик белдерә. Әйтик, машина гаиләнең уртак мөлкәте булып санала икән, ни өчен әле ире кылган гөнаһ өчен хатынына да җавап тотарга туры килә? Арендага алынган машинада йөргәндә кагыйдә бозу очраклары белән дә охшаш сораулар калкып чыга. Андый автомобильгә кагылмыйлар, ә үзенеке белән эләксә, тәпи-тәпи йөрергә туры киләчәк.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары, отставкадагы генерал Рафил Ногманов әйтүенчә, кырыс чараларсыз юлда тәртип салып булмый.

– Моннан 5–6 ел элек Германиядән кайтып барабыз. Очкычка соңга калабыз, аэропортка ашыгабыз. Ә такси йөртүче тизрәк бару турында уйлап та карамый икән. 500 евро түләсәгез дә чапмыйм, 7 штрафым бар, 8 нчесе килсә, правасыз калам, аннары тиз генә рульгә утыра алмыйм, ди. Юл тәрбиясе дип күпме генә сөйләсәк тә, ни булганны көн саен күреп торабыз. Исерек йөртүчеләр элек тә куркытты, хәзер дә шулай. ГАИга эш бетми, рейдлар вакытында күпме кеше эләгә. Аларны сүз белән генә акылга утыртып булмый. Барыбер аңламыйлар. Машинага якын да китерергә ярамый. Шуңа күрә мин бу үзгәрешләрне хуплыйм. 150 мең генә түгел, 10ар миллион сумлык машиналарда йөрүчеләр бар бит. Үзе эләккәндә соң була инде, бәлки, башкалардан күреп сабак алырлар, – ди ул.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе хезмәткәрләре: аеруча мөһим эшләрне тикшерү буенча өченче бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция полковнигы **Сыраев** Илнур Гайфетдин улына, беренче контроль-тикшерү бүлеге җитәкчесе урынбасары, юстиция подполковнигы **Хафизов** Артур Вакыйф улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ГӨМБӘЧЕЛӘР АВЫЛЫ

Әгерҗе районының Яморза авылы халкы, гөмбә, җиләк җыеп, себерке бәйләп акча эшли. Хәер, гомер буе буыннан-буынга күчә килгән кәсеп авыл халкына матди файда гына түгел, рухи азык та бирә. «Без гөмбә сезонын түземсезлек белән көтеп алабыз. Хәтта төшләребезгә кереп җәфалый ул», – дип көлә ирле-хатынлы Чулпан һәм Алмаз Хикмәтуллиннар. Җитмәсә, быел сезонны да күпкә алданрак ачканнар.

– Җәй, көз айларында гөмбә җыяр өчен яңгыр яуганын көтәбез. Безнең сезон гадәттә августта башлана. Ләкин быел яз, җәй башлары яңгырлы килгәч, июльгә кадәр көн дә урманнан кайтып кермәдек, – ди алар.

Бу яклар урманнарга бик бай. Ә халкы иң тәмле һәм затлы гөмбәдән саналган ак гөмбә җыя. Моннан тыш, урманда гөреҗдә, баллы гөмбә (опята) дә күп. Әле җитмәсә, башка төбәкләрдән, шәһәрләрдән дә киләләр икән. Шимбә-ял көннәрендә урманга бармавың хәерле, ди алар. Чөнки бу көннәрдә урман Сабан туе мәйданын хәтерләтә.

– Без – тумышыбыз, нәселебез белән шушы авылныкылар, – ди Чулпан Хикмәтуллина. – Кечкенә чакта авыл башында җыю пункты бар иде. Халык шунда барысы да гөмбә тапшырды. Ул елларда гөмбәне көянтәләп ташый торган идек. Кая куйганнардыр аларны, әйтә алмыйм. Бала булгач, әллә ни игътибарга да алынмаган. Хәзер дә җыйсыннар иде аны, бик яхшы булыр иде. Гөмбә җыю безнең каныбызга сеңгән. Дөрес, ул елларда гөмбә дә күбрәк җыела, урманнар да баерак, зуррак иде. Гөмбәне 60–70ләп банка маринадлый торган идек. Әнкәй әле дә булса күңеле белән урманнарда йөри. Кызганыч, хәзер мөмкинлеге генә юк. Ике аягына да операция ясатты. Шулай да быел: «Урманга барасың киләме?» – дип сорадым. «Килә», – дигәч, ике көн алып бардык. Машинадан төшә дә, мин борылганчы, юкка да чыга. Гомер буе гөмбә җыйган кешенең хис-кичерешен шуннан аңлагыз инде сез.

Гомумән, яморзалылар барысы да – тырыш халык. Табигать биргән нигъмәтнең файдасын күрәләр.

– Элек бездә нефтьчеләр эшләде. Халык ашлы да, эшле дә булды. Хәзер кешегә эш бетте, ике тулай торак бинасы бушап калды. Терлекчелек белән дә шөгыльләнмиләр бездә. Көтү күптән чыкмый инде, сөтлебикәләр дә бер-ике кешедә генә бар. Шуңа күрә халык ничек булдыра ала, шулай тормыш итә. Җиләк, гөмбә җыя. Себерке бәйләп сатучылар да, яшелчәчелек белән шөгыльләнүчеләр дә күп. Себеркене Ижау, Чаллыдан килеп алып китәләр. Сорау күп, ул яктан авырлык юк, – ди алар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хикмәтуллиннар әйтүенчә, урманның иң матур вакыты – таң белән.

– Быел гөмбә чорында көн саен сәгать 2дә йокыдан торып, 3 тулганчы урманга барып җитә торган идек. Табигатьнең иң матур вакыты ул. Матурлыктан, рәхәтлектән башлар әйләнә. Гөмбә күбрәк чыкса, сәгать 6ларда кайтабыз. Гадәттә бер барганда 10 литрлы чиләкне тутырып алып кайтырга тырышабыз, – ди Чулпан ханым. – Безнең якларда аюлар, боланнар, селәүсеннәр (рысь) дә бар. Тик минем аю күргәнем юк әле. Аның каравы беркөнне сеңлемә очраган. Бер-беребезгә карашып тордык, диде. Күрше авылда ике баласын иярткән аюны да күргәннәр. Хуҗалыкка төшүен төшмиләр үзләре. Тик урман территориясендә, юл яннарында әледән-әле күреп торалар аларны.

– Мин дә эштән кайткач, үз юлым белән гөмбәгә китәм, – дип сүзгә кушыла гаилә башлыгы Алмаз абый. – Бик яратабыз гөмбә җыюны. Төшләргә керә бит ул. Азарт белән җыябыз. Быел каен җиләге дә бик мулдан булды.

Ак гөмбәне каенлыкта ачык урыннарда табарга була икән. Яңгыр явып узса яки томан төшсә, гөмбәчеләрне бәхет баса инде. Хикмәтуллиннар гөмбәне тозлый, маринадлый, катырып куя, киптерә. Сораучы булса, сатып та җибәрәләр икән. Хәер, шушы еллар эчендә үз клиентлары да барлыкка килгән. Көтеп кенә торалар, ди. Быел ак гөмбәнең өч литрлы банкасы 1500 сум торган. Киптерелгәненең бер килограммы 3000 сум тирәсе чыга. Моның өчен 10 чиләк гөмбә киптерергә кирәк. Алар исә бер барганда 10 литрлы чиләк тутырып кайта. Гөмбә аеруча мул булган елларда 4–5әр чиләк тә җыйганнары булган. Кыскасы, зур тырышлык һәм үҗәтлек таләп итә торган хезмәт.

– Гөмбәне башта кояшта, аннан соң махсус савытта киптерәбез. Кирәк булса, иттарткыч аша да чыгарабыз. Кышын аны ашларга, икенче ризыкларга, пиццага салабыз. Гөмбә җыярга яратсак та, ашарга бик һушыбыз китми. Әллә нигә бер, башкалар кебек үк тансыкка гына кулланабыз, – ди хуҗабикә.

ГӨМБӘ МАРИНАДЛАУ РЕЦЕПТЫ

Гөмбәне чистартып турагач, ярты сәгать тирәсе пешереп алабыз. Сүндергәч, салкын су белән юдырабыз, аннан тагын плитәгә куеп, тоз салып, кайнатып чыгарабыз. Маринадын аерым ясыйбыз. 3 литр суга 2 чәй кашыгы тоз, бер аш кашыгы серкә кислотасы, лавр яфрагы, кара борыч салабыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Авылга да, шәһәргә дә файдалы

1–7 август көннәрендә Кукмара районының Вахит авылында «Авылга да, шәһәргә дә» арт-резиденциясе эшләячәк. Әлеге уникаль проект Россиянең Мәдәни инициативалар фонды ярдәме белән гамәлгә ашырыла.

Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әйтүенчә, проектта Кукмара, Саба, Балтач һәм Мамадыш районнары катнаша. Казаннан да гариза тапшыручылар бар икән. Оештыручылар әйтүенчә, әлеге проект киләчәктә башка зоналарда да тормышка ашарга мөмкин. Ни өчен бу юлы мондый чара Кукмара районының Вахит авылында уза соң? Журналистларны әнә шул сорау да кызыксындырды. Баксаң, проектны алар үзләре тәкъдим итеп, грант алуга ирешкән икән. Гомумән, матбугат очрашуында Кукмара районының барлык проектларда активлык күрсәтүен билгеләп уздылар.

Проектның сәнгать җитәкчесе Гөлфия Мотыйгуллина фикеренчә, авылда да менә дигән чаралар оештырырга мөмкин. Әлеге резиденция исә Нәфыйк Хөсәенов исемендәге паркта узачак. Анда катнашырга теләк белдереп, 50гә якын кеше мөрәҗәгать иткән. Проектта исә аларның 24е катнашачак. Калганнар тамашачы булып киләчәк. Алар өч юнәлеш буенча эшләячәкләр: музыка, архитектура, экскурсия. Барысы да – 35 яшькә кадәр булган яшьләр.

Кукмара районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Айгөл Әхмәтшина әйтүенчә, бер атна дәвамында яшьләр заманча белем алачак.

– Бүген яшьләр авылдагы матур, уңайлы шартларны аңлап бетерми. Алар барысы да элеккечә дип күзаллый. Узган ел безгә бөтен Россиядән студентлар килгән иде. Алар да авылдагы шартларны, матурлыкны күреп гаҗәпләнде. Кыскасы, без авылга да, шәһәргә дә файдалы булган лайфхаклар ачачакбыз, – диде җитәкче.

Татарстанның Традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры Алсу Мифтахова уңышлы объектларга яхшы кадрлар таба алмау проблемасы барлыгын әйтте.

– Авылны яратыр өчен, аңа башка күзлектән карарга кирәк. Әлеге проектның кураторлары кешеләргә дөньяга башка күзлектән карарга ярдәм итә. Нәтиҗәдә Вахит авылы гади авыл кебек кенә кабул ителми, – диде ул.

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авылкаем

Мең-мең бәхет юллар чакта,
Ягым, сиңа тиң калам.
Авылның яшел чирәмен
Сагына һәрбер балаң.

Юк, китмимен, һич китмимен
Мин синнән, авылкаем.
Ак каенлы, җил капкалы,
Газиз туган яккаем.

Ай нурыдай якты иде
Авылдагы вакытлар.
Учак янында кичләрен,
Их, күңелле уеннар!

Зифа юкәләрең белән
Кызыктырма син, калам –
Кайда җиләк болыннарың,
Яшел чирәмең кайда?

Рамил ЧУРАГУЛОВ

Оныгың белән нинди телдә сөйләшәсең?

Хәзер күп әти-әни, тынычлыкта калдырсын дип, юньләп сөйләшә дә белмәгән баласына телефон, планшет тоттыра. Сабыйларның интернетта утырып, гаджетларда уйнавы, әти-әни, әби-бабай белән сирәк аралашуы сакаулыкка, теле соң ачылуга китерә. Аннан, баланы җитәкләп, логопедка чабалар, күп акча түгеп, сөйләшергә өйрәтәләр. Шуларны уйлап йөрдем дә, борчылган сорауларыма җавап эзләп, Каюм Насыйри премиясен алган, 2015 елда «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» исеменә лаек булып, миллион сумлык грант откан, 2016 елдан белем һәм тәрбия бирүдә татар телен өйрәтү буенча республикакүләм эксперименталь мәйданчык итеп билгеләнгән Карадуган авылының «Ак каен» балалар бакчасына юл тоттым.

Сак кына ишеген ачып керүгә, «Оныгың белән нинди телдә сөйләшәсең?» дигән шигырьгә тап булдым, аннан диварлары милли орнамент белән завыклы итеп бизәлгән сихри балачак дөньясына чумдым. Ак каен рәвешендә эшләнгән ясле-бакча шәҗәрәсе үзе генә дә ни тора?! 42 ел эчендә монда кемнәр хезмәт куйган – барысы да тарихка кергән! Тамыры – нигез ташын салудан алып 33 ел шушы бакчаны җитәкләгән, күп методик әсбаплар, шөгыль эшләнмәләре авторы – Зөлфирә Камалова.

Мине мөдир Зәһрә Бәдретдинова ачык йөз белән каршы алды. Ул – югары белемле чит тел белгече, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен укыту-методик әсбаплар авторы. Тәрбиячеләр нәселеннән. Әнисе Зөлфирә, аның апасы Фатыйма – бакча мөдирләре, әбисе Шәрифелҗамал шунда эшләгән. Зәһрә ханым нәсел һөнәрен йөзгә тап төшермәслек итеп башкара. Бергәләп төркемнәргә үтәбез.

Тәрбиячеләр дә, балалар да милли киемнәрдән, калфак-түбәтәйләрдән. Без кергән бүлмә куркак өен хәтерләтә. Бирелдә татарча сөйләшүче керпе, куян, эт, кыз, малай курчаклар. Татарча җырлаучы, сөйләшүче китаплар, уеннар, мультфильмнар. Тәҗрибәле педагог Нәҗия Хәйруллина белән яшь педагог Илүзә Хәсәнова балалар белән бергәләп мультфильмнар төшерә икән. Уенчыкларны да бергәләп ясыйлар. Габдулла Тукай, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин, Фәридә Шакирова һәм башкаларның шигырьләрен, әкиятләрне рольләргә бүлеп, театр итеп уйнарга да яраталар икән. Шулай кечкенәдән сәхнәдә үз-үзләрен тотарга, сәнгатьле сөйләм күнекмәләренә дә өйрәнәләр. Икенче бүлмәгә үтәбез. Биредә Лилия апалары кызларны тегү-чигү серләренә өйрәтә. Әле Раушания апаларыннан бәйләү осталыгына да өйрәнәләр икән. Тагын бер төркемгә керсәк, малайлар, кызлар Гөлнур апалары белән токмач җәяргә өйрәнеп маташалар! Кайсы бүлмәгә керсәк тә, матур итеп саф татарча исәнләшәләр, сорауларыма җавапка да кесәгә кермиләр. Үземне дә сорауларга күмделәр. Җавап биреп кенә өлгер!

«Ак каен» ясле-бакча хезмәткәрләре һәр зур чараны әти-әниләр белән киңәшләшеп, ярдәмләшеп үткәрәләр. Балаларның сәләтләрен һәрьяклап үстерү максатыннан төрле түгәрәкләр эшли. «Мульт-студия «Art-Sәlәt», «Тылсымлы ком», «Әдәп төбе – матур гадәт», «Тылсымлы бармаклар», «Әпипә», «Тургай» түгәрәкләре – әнә шундыйлар.

Бакчага гел татар балалары гына йөрсә дә, алар башка милләтләр белән дус яшәргә кирәклеген белеп үсәләр. Музыка җитәкчесе Илһамия апалары белән удмурт, рус, керәшен, марийларның уеннарын, җыр-биюләрен, милли кием үзенчәлекләрен өйрәнәләр, бездә бәйрәмнәр белән чагыштыралар.

Ясле-бакчада иң күркәм гамәлләрнең берсе – «Балачак иле» музее. Биредә бик күп чаралар, экскурсияләр, тематик кичәләр дә уздырыла. Менә чыбылдыклы агач караватыт читендә тирбәлүче бишек. Ана баласын тирбәтә. Ап-ак мичле авыл өе. Мич алдында – комган, шүрлектәге ак тастымал өстендә – Коръән, тәсбих, кучкарда – түбәтәй. Борынгы уенчыкларның күплеге таң калдыра. Бишекләрнең нинди генә юк?! Кабык бишек, тал бишек, агач бишек. Ул ятмалары тагын! Бәби арбалары да төрле-төрле. Биредә йөргәндә балачак хатирәләре яңара.

«Ак каен» кебек милли рухта тәрбияләүче, уйларга, фикерләргә, һөнәргә өйрәтүче бакчалар күбрәк булса, безнең арттан милләтне, гореф-гадәтләрне, татар телебезне кадерләп-саклап, киләчәккә тапшырырдай буын үсеп килә, дип ышанып әйтергә мөмкин.

Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА.
Балтач районы Шубан авылы

Мөхәррәмов эзләре

Татарстан Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты профессоры Мидхәт Мөхәррәмовның 100 еллыгын билгеләп үтте. Ул 70 яшенә кадәр унлап китап, ике йөздән артык фәнни мәкалә язган.

Танылган татар язучысы Мирсәй Әмирнең «Мидхәт» дигән мәкаләсендә менә мондый юллар бар: «Правда» газетасының 1942 ел, 1 октябрь санында «Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак» дигән исем астында бер хәбәр басылган. Фашистлар артиллериялләр белән маневр ясап, безнең танклар һөҗүмгә барган урыннарны көчле ут астында тоталар. Шулай булуга да карамастан, безнең Мөхәррәмов, Глушков һәм башкалар командалыгындагы танкларыбыз дошман көчләре тупланган җирләргә үтеп керә алдылар һәм немецларның шактый тупларын һәм минометларын юк иттеләр». Моннан соң тагын бик күп сугышларда катнаша әле ул. Танк эчендә яна башлый. Ә 1944 елның гыйнварында булган сугышларның берсендә бер аягын калдырып чыга. Ике тапкыр Ватан сугышы ордены, ике тапкыр Кызыл Йолдыз ордены, Ленин ордены белән бүләкләнә.

22 яшеннән гарип калган егет, културык таякларына таянып, дүрт еллык Казан юридик институтын бик яхшы билгеләргә генә өч елда тәмамлый. Шушы ук елны СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасына керә. 1958 елда аның рус телендә «Октябрь һәм Татарстанда милли мәсьәлә» дигән китабы дөнья күрә. Татар халкы, Татарстан халыклары тарихы буенча иң күп мирас калдырган галимнәрнең берсе ул Мидхәт абый. Төбәк тарихын яхшы белгәнгә, аның хезмәтләрендә яңа исемнәр табасың. Аларны ул җәмәгатьчелеккә күрсәтү өчен күпләп китерә.

Сигез ел буе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми секретаре, 5 ел тарих секторы мөдире, 20 елга якын институт директоры булу фән белән шөгыльләнергә күп вакыт калдырмый, әлбәттә. Әмма Мидхәт Кәримович союз масштабында укучыга барып ирешерлек хезмәтләр чыгаруны мөһим эш итеп саный. Мәскәүгә институт эшләре белән баргач, «Наука» нәшрияты җитәкчеләре белән сөйләшүләр алып бара. Ниһаять, бернигә саллы хезмәтне бастыруга рөхсәт ала. Тиздән бу нәшриятта берсе артыннан берсе коллектив монографияләр дөнья күрә. Болардан тыш «Энциклопедия» нәшриятында «Татарско-русский словарь» басылып, югары бәя ала.

Җитәкче социаль мәсьәләләрне дә кайгырта. Фатирга мохтаҗ хезмәткәрләр артканнан-арта баргач, бу хакта СССР Фәннәр академиясе Президиумына хатлар яза. Үтенеч белән Мәскәүгә үзе бара. Нәтиҗәдә Казан шәһәр Советы «өлешләп катнашу» кысасында институтка 30дан артык (10 ел эчендә) фатир бүлеп бирә. Монда, әлбәттә, директор Мөхәррәмовның куйган тырышлыгы бәхәссез. Мондый нечкәлекләрне без, хезмәткәрләр, хәтта белмәдек тә. Ярый әле бу хакта аның фән буенча урынбасары Илбарис Надиров «Незаурядная личность» китабында язып калдыра. Үзе турында Мидхәт абый, гомумән, беркайчан да сөйләми иде. Аның яхшы галимнәрне әзерләүдәге роле дә игътибарга лаек.

Ул җәмәгать эшләрендә дә актив катнашты. Казан шәһәренең халык депутатлары Советы депутаты иде. «Казан утлары», «Совет мәктәбе» журналлары редколлегиясе, Габдулла Тукай исемендәге республика премиясе комитеты әгъзасы булды. Күп еллар буе Татарстан партия өлкә комитеты ревизия комиссиясе һәм төрле фәнни советлар составына да сайланды. Зур тырышлыгы аны республикага гына түгел, бөтен илебезгә танытты. Ул – Татарстан һәм Россиянең атказанган фән хезмәткәре.

Мидхәт абый тормышында да матур эз калдырды. Хәләл җефете, укытучы Фәридә Абдулхак кызы белән бер бөтен булып яшәделәр. Уллары Шамил һәм Наил, киленнәре Ләйсән фәндә тагын да югарырак баскычларга күтәрелде.

Зөбәрҗәт ГАРИПОВА.
Казан

Авыл зираты хикмәтләре

Бик борынгы заманнардан бирле зиратлар серле һәм безгә урын булып саналган. Буа районы Карлы авылында да шулай. Нинди авыр чор булса да, анда үскән куакларның җимешләрен ашамаганнар, җирдә үскән җиләкләрен җыймаганнар. Хәтта корыган агач-куакларны утынга да кулланмаганнар. Карлы авылы 1662 елда оешкан, димәк, шул вакыттан бирле анда кешеләр җирләнә башлаган. Һәр нәрсәнең хуҗасы булган кебек, зиратларның да хуҗалары бар. Моның шулай икәнен дәлилләр өчен берничә мисал китерергә мөмкин.

Таш яңгыры

Бу хәл 1947 елның көзендә була. Әнием Сания күршебез Зәйнәп апа белән иртәнге сәгать 4ләр тирәсендә колхоз амбары янына эшкә барырга чыга. Тизрәк эшкә керешер өчен кладовщик Сиразетдин бабайны үзләре белән алып китәргә булалар. Аның йортына барыр өчен зират яныннан үтәргә кирәк. «Акрын гына тормыш хәлләрен сөйләшә-сөйләшә, зират янына җитеп күп тә үтмәдек, кинәт кенә өстебезгә, шаулап, вак таш яңгыры ява башлады. Нәкъ бозлы яңгыр кебек! Куркуыбыздан бер-беребезгә тотынышып йөгерә башладык. Таш яңгыры Сиразетдин бабай йортына кадәр куа килде. Ишекне бәреп кердек тә, һушыбыз китеп, идәнгә егылдык. Күргән хәлне сөйләгәч, зират янына якынлашканда, әрвахларга догалар укырга иде, диде бабай, аннары өстәп, таң атмаган, яктырганчы зиратларга алар хуҗа, диде», – дип сөйләде әнием.

Сәер тавыш

Бу хәл 1975 елда була. Бер көнне Фәһимә апаның көтүдән сарыклары кайтмый. Кояш баер вакыт җитәрәк ул аларны эзләргә чыга. Чөнки авылда хуҗасыз этләрнең сарыкларга һөҗүм итү очраклары еш булып тора. Инде кояш баеп, караңгы төшә башлаганда, авыл зираты тирәсендә бер төркем сарык күреп ала. Үзенекеләрне танып алып, авылга таба куарга керешә. Шулчак зират ягындагы җир астыннан бик каты ачынып-борчылып кычкырган тавыш ишетелә. Фәһимә апа, коты очып, юл аша яшәүче Мәрьям апа өенә кереп егыла. Иртән, тынычлангач, авыл мулласы Нургали абыйга бу хәлне сөйләп бирә. Соңыннан шул ачыклана: Карлы авылына башка районнан, ялгыз яшәргә хәлләре авырайгач, кызы янына бер әби килгән булган. Җәйле җитеп вафат булгач, аны шул көнне күмгәннәр. Элек авылның авыл халкын чукындырган булганнар. Күрәсең, әби ислам диненә кайтып, иманын яңартмаган. Коточкыч каты тавыш шул әби күмелгән кабер ягыннан булган. Имансыз мәетне шулай ризасызлык белән каршылаганнар.

Расих ҖӘЛӘЛ.
Казан

Сөйлим анам телендә

Туган телебезне үстерүгә һәм сакларга өлеш кертеп, Түбән Кама шәһәренең «Апуш» балалар китапханәсендә «Сөйлим анам телендә» дип исемләнгән бәйге уздырдык. Анда 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар шигырь сөйләү осталыгында ярыштылар.

Әйтергә кирәк: кечкенә нәфис сүз осталары арасында көндәшлек көчле булды. Беренче этапта 60 бала онлайн рәвештә ана телебезгә багышланган шигырьләрен тәкъдим иткән булса, финалда 20 бала катнашты. Финал өлеше «Сөембикә» исемле 64 нче номерлы балалар бакчасында тәрбияләнүче балалардан торган ансамбльнең «Үз җырыбыз булсын әле» дип исемләнгән чыгышы белән башланып китте. Балаларны бәйгегә әзерләгән тәрбиячеләргә, музыка белгечләренә мактау кәгазьләре, нәфис сүз осталарына дипломнар, сертификатлар, «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы тарафыннан әзерләнгән бүләкләр өләшенде.

«Ак калфак» оешмасының җирле бүлеге җитәкчесе Гөлсинә Галиуллина шәһәрдә телебезне яклаучы, саклаучы балаларның күп булуына сөенүен белдерде, алга таба да туган телебездә китаплар укырга, әдипләребезнең иҗатларын белергә, алдагы бәйгеләрдә аларның шигырьләрен дә файдаланырга, гомумән, милләтебезнең лаеклы дәвамчылары булырга чакырды.

Гөләмия САБИРОВА.
Түбән Кама

Хәзинәләр бар әле

Авыл китапханәсе каршында «Хатирә» клубы оешуга ике дистәдән артык ел узып та киткән. Аны без лаеклы ялга чыккан авылдашлар туплансыннар, гомер буе бергә эшләгән коллективларыннан аерылган пенсионерлар ямансулап утырмасыннар, ялларын күңеллерәк, эчтәлеклерәк итеп уздырсыннар дигән нияттән оештырган идек.

Чыннан да, шушы вакыт эчендә бик кызыклы чаралар уздырылды. Күренекле язучыларның юбилейларын билгеләп үттек. Авылдагы сугыш ветераннарын, репрессия корбаннарының туган-тумачаларын кунакка чакырдык. Сугыш һәм аннан соңгы авыр елларда торф чыгарырга, урман кисәргә мәҗбүри җибәрелгән, бер авыз русча белмәгән авыл кызлары, аларның балалары белән истәлекләр барлап утырдык. Соңгы елларда клубка мәктәп балалары да актив йөри башлады. Алар өчен олы яшьтәге өлкәннәребездән авылыбыз тарихын сөйләтеп калу максатында очрашулар уздырабыз.

Телебез бетә дип хафаланабыз. Борынгы гореф-гадәтләрне ешрак искә төшерсәк, балаларыбызны бу эшкә җәлеп итеп, милли горурлык уята алсак, милләтебез яшәр. Һәр кичәгә, һәр очрашуга әзерләнгәндә мин шушы мөһим мәсьәләгә игътибар итәргә тырышам.

Истә калырлык итеп «Яулык бәйрәме» уздырган идек. Эзләнә торгач, нинди генә хатирәләр калкып чыкмады. Күп еллар сандыкларда төбендә саклана торган, кайчандыр әбекәйләребез бәйләп йөргән яулыкларны клубка алып килдек. Бар икән әле андый хәзинәләр! Хәнифә апа Вәҗиева, мәсәлән, бабасының Беренче Бөтендөнья сугышыннан әбисенә бүләккә алып кайткан, йөз елдан артык сакланган парча яулыкны алып килгән иде. Эшләп тә караганнар инде – төсен дә җуймаган. Нәсимә Биктимерова моннан ярты гасыр элек килен булып төшкәндә каенанасы бүләк иткән шәльяулыкны саклаган. Тәгъзимә Гыйззәтуллина алып килгән яулыклар да күз явын алырлык. Әле күптән түгел мәктәп укучылары белән «Май канаты үрә беләсезме?» дигән мастер-класс үткәрдек. Балалар, бик тырышып, май канаты үрергә өйрәнделәр. Борынгы йолаларыбызның берсе – «Кич утыру» мәҗлесе дә уздырган идек. Анда һәркем үз белән кул эше алып килде. Йон язып-эрләп, оекбаш-башмаклар бәйләп, мәш килдек. Дөрес, кем әйтмешли, хәзер интегеп утырасы да юк: кибетләр, базар тулы ул эшләнмәләр. Әмма авыл кешесе бик тынгысыз, әзерге әйрәнмәгән, үз тырышлыгы белән муллык тудырырга күнеккән. Үз кулларың белән бәйләнгән әйберләргә кул җылысы, күңел җылысы салына. Әбиләребез, әниләребез яратып җырлаган җырларны җырлап, аулак өйләрдә уйнаган уеннарны, яшь чакларны искә төшереп, гөрләшеп кич утырдык. Ике баянчы егетебез дә килгән иде, рәхәтләнеп җырладык-биедек. Табышмак-мәкаль, тизәйткечләр әйтешү үзе бер ярышка әйләнде. Борынгы йолаларыбыз, аларның телебезне, динебезне, милләтебезне саклаудагы роле турында әңгәмәдән соң һәркем әзерләп алып килгән камыр ризыкларыннан чәй өстәле әзерләдек. Бергә-бергә барыбер күңелле инде. Истәлекләрне яңарттык, кайгы-шатлыкларны уртаклаштык, борынгы йолаларыбызны барладык, киләсе очрашуларның тематикасы турында киңәшләштек. Кул эшләре күргәзмәсендәге бәйләнгән бәйләм үрнәкләре клубка йөрүчеләргә осталыкка этәргеч тә биргәндер. Һәрхәлдә, очрашу күңелләрдә яктылык, бәйрәм хисе калдырды.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА.
Тукай районы Күзкәй авылы

Автор фотосы

Россия – минем тарих

Казанның Яңа Савин районында урнашкан «Простор» балалар-үсмерләр туризм һәм сәяхәтләр үзәге укучылар иҗаты өчен төрле мөмкинлекләр ача. Россия Федерациясенең атказанган мәгариф хезмәткәре Рафаэль Фазлыев җитәкчелегендә балаларны ватанпәрвәр итеп тәрбияләүче педагоглар эшли. Алар малай һәм кызларга күңел җылысын өләшә. Үзәктә төрле чаралар үтә, мәктәп-гимназияләрдә төрле бәйге-ярышлар уздырыла. «Россия – минем тарих» 4 нче төбәкара фәнни-гамәли конференциягә дә йөзләп укучы җыелган иде. Чара «Казан чыклары» фольклор ансамбль чыгышы белән башланды. Чуашстан Республикасының Шумерля шәһәреннән килгән «Ника» барабанчылар ансамбле үзләренең дәртле чыгышлары бүләк иттеләр. Идел буе халыкларының милли йолаларына, бәйрәмнәренә, кyрәнекле шәхесләребезгә, бишек җырларына, милли ризыкларга багышланган чыгышлар күңелдә якты хатирә калдырды.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан

Язучы фикере

Разведчик

Бәләкәй чакта мин разведчик булырга тели идем…

Бу хыялның сәбәпләре күп төрле булды инде. Беренчедән, без – Николай Кузнецов, Максим Исаев кебек разведчиклар турында кинолар карап үскән буын. И ул чорда кем генә Штирлиц булырга теләмәде икән? Штирлиц ук булмаса да, яхшы разведчик. Заман шаукымы буларак патриотизм тойгысы да көчле иде. Без октябрят, пионер булып әкият илендә үстек, мифлар белән тукландык, әкияттә яшәдек бит инде. Әкият тә чынбарлык шикелле иде. Сугыштан әйләнеп кайта алмаган дәү әтиләр батырлыгы. Тылдагы дәү әниләр каһарманлыгы. Болары инде әкият түгел, ә өлкәннәребезнең үз авызыннан өзелеп төшкән вакыйгалар, тарих иде. Утыз ике яшеннән тол калган әбием кырык ел буена ирен көтте, җан бирер алдыннан да: «Кайтмады инде…» – дип авыр сулап куйды. Монысы инде тарих кына да түгел, ә безнең гомернең бер өлеше кебек.

Разведчик кызыктыра торган һөнәр инде ул. Мәңге чыгып булмастай тоелган вакыйгаларны үзенә буйсындыра ала, сугыша белә, ата белә, урлаша белә… Савымчылык фермасыннан салам, он, сөт урлап кайткан чакларда мин дә үземне разведчик кебек тоя идем. Кирәк җирдә ятып каласың, кирәге чыкса, йөгерәсең… Яткан җирдән атып та ятасың әле, бармагыңны пистолет итеп. Тотылсаң, нәрсәдер дип акланырга тырышасың, алдашасың. Кызык инде барысы да. Разведчиклар әле яхшы итеп сугыша да белә. Аларны шуңа да өйрәтәләр. Әтигә әйтәм, абыйга әйтәм, дип куркытырлык кешесе булмаган малай өчен монысы да соңгы урында түгел әле аның. Мин дә шулар кебек ныклы булырга тырышып, спорт белән шөгыльләнә идем. Кышларын бот тиңентен кар ярып йөгерәм, җир ачылгач, катканаклардан, ташлы комнан яланаяк чабам. Аякларга сөял чыгып бетә, алар берни сизми, үземне тукмарга теләгән олы малайлардан шайтан таяклары арасына кереп качам. Алар керәлмиләр – аякларында сөял юк чөнки. Десантта яки погранда хезмәт итеп кайткан абыйларга барып берәр «прием» өйрәтүләрен үтенәм. Прием ул – сугыш алымы. Ул кирәк, чөнки авыл малайлары арасында сугышканда көтелмәгәнчәрәк итеп җиңсәң, шундук даның тарала, «Ул бит приемнар белә», – диләр. Бот буе малайны сугышырга өйрәтергә берәү дә атлыгып тормый инде. Тик җаен табарга тиешсең, син бит – разведчик… Кайчагында нindидер йомышларын үтисең. Ну, нindидер кызга чәчәк бүләк итәсең, ярату хаты тапшырасың. Һич югында таллыктан сәнәк сабы кисеп алып кайтасың. Өйрәтәләр. Шул алымны иптәш малайларың белән кабатлыйсың, шомарып беткәч, берәрсе белән сугышып карыйсың…

Без бәләкәй чакта Гитлер юк иде инде. Бабайлар аны дөмектергән. Без үзебезнең шул сугышта катнашып, батыр икәнебезне күрсәтергә өлгермәвебез өчен дә, туган илебезгә файда китерә алмавыбыз өчен дә бик үкенә торган идек. Ил кадерле иде безнең өчен. Ватанпәрвәрләр идек. Аның дошманы – безнең дә дошман, ул ни кушса, шуңа әзер идек. Без үсмер чакта Әфган сугышы бар иде. Минем кебек сугыш чукмарларының барысы да шунда барып, батыр булып кайтырга хыяллана иде. Гарипләнгән яки табутта кайткан авылдашларыбыз булса да, без үлем турында уйламый идек.

– Кто хочет в Афган? – ди училищедагы хәрби әзерлек дәресенә килгән военкомат вәкиле. ДШБ лейтенанты ул. Хәрби киеме үк үзенә чакырып тора торган кеше. Курсантлар тын кала. Бер мизгелгә. Сизеп торам инде, йөрәк тибешләре ешая, күзләрдә очкын уйный. Үземдә дә шул халәт, хәтта тез буыннары йомшарып китә.

– Мин!

Бөтен рәт бер адым алга атлый. Бер мин урында калам.

– Кәбиров? – дип сораулы карашын төби хәрби җитәкчебез Хафизов абый.

Мин дәшмим. Мин бик гади малай түгел бит инде, юкка гына үземне разведкага әзерләмәгәнмен. Мондый сорауларның нәрсә икәнен күптән белеп торам. Әгәр син берсүзсез алга чыгасың икән – алмыйлар. Бер уйсыз ура-патриотлар рәтенә кертеп калдыралар. Чөнки сугыш ул уен түгел, батырлыкка омтылган уйсыз малайлар беренче һәлак була. Әгәр Әфганга эләгергә телисең икән, моны беркемгә дә сиздермәскә кирәк. Мин сиздермим. Разведчик салкын канлы булырга тиеш бит инде. Елар урында да елмаерга тиеш…

– Кабиров, три шага вперед!

Мин атлыйм. Һәм күңелемнән генә үземнең иптәшләремнән өч адым алдарак икәнемә сөенәм. Разведчик берничә адымга алдарак булырга тиеш. Хәрби җитәкчебез кыскача гына кемлегемне әйтеп ала. Озын-озак сөйләрлек биографиям дә, мактаулы исемнәрем дә юк бит инде. Спортсмен, хулиган, шагыйрь. «Шагыйрь» диюен яратмыйм, ләкин калган параметрлар туры килә. ДШБ лейтенанты да канәгать…

Тик… Безнең авылның бер кызык кешесе бар иде. Үзен хәтерләмим инде, беркем дә хәтерләми бугай. Әмма сүзен хәтерлиләр: «Самый кирәк чакта хатын үлде…» Мин армиягә китәр алдыннан гына хәрбиләрне Әфганнан чыгардылар. Соңрак, гаилә хәле авыр дип, үземне дә армиягә чакырмадылар. Мин – Әфганда ДШБда хезмәт итәргә тиешле кеше, Әфган сугышыннан да, десант штурм батальоныннан да – барысыннан да коры калдым. Разведчик та була алмадым. Кузнецов, Исаев сыман… Түздем инде. Хыялларның, максатларның челпәрәмә килүенә бәләкәйдән күнеккән кеше буларак та. Үзен разведкага әзерләгән егет буларак та.

Мин язучы булдым. Үзем күргән-тойган-кичергән нәрсәләрне сезгә җиткереп бардым. Түкми-чәчми. Ничек бар – шулай. Вакыты белән юаттым да, елаттым да, уйландырдым да бугай. Мин – сезгә мәгълүмат, хис-тойгылар ирештерүче. Сез менә алмаган таулар түбәсеннән, сез төшә алмаган упкыннар һәм сазлыклар төбеннән. Сез керә алмаган, сез күрә алмаган дөньялардан. Разведчик инде, кыскасы.

Мин хәзер хәрби кеше булырга теләмим инде. Сугыш та теләмим. Кешеләрнең сугышуларын да, бер-берсен сатуларын да, урлашуларын да, үтерешүләрен дә теләмим. Тыныч булып, тынышып яшәргә кирәк дип уйлыйм. Хыялларыбыз һәм нәфселәребез чиксез булса да, гомерләребез чикләнгән. Кеше гомере белән сак булырга кирәк. Һәр мизгелдә. Һәр мизгелдә кешеләрнең һәм үзеңнең гомереңне саклап, матурлап яшәргә кирәк. Без бәлки шуның өчен яралтылганбыздыр. Бу дөньяның һәрбер авырлыгын матурлыкка әйләндерергә тиешбездер. Акчага да, шәхси амбицияләр уенына да түгел, ә матурлыкка. Матурлыкка.

Тик кайвакыт үземне разведчик итеп тоям. Дошман тылындагы сыман. Иң якын дусларым иң якын дошманыма әйләнә. Якыннар ерагаймый ул, алар үзгәрә генә. Таш дип таянганнарым ком булып ишелә. Ком дип чокыганнарым таш булып чыга. Гомерләрнең бер чорына җиткәч, барыбыз да шундыйрак хәлгә калабыздыр инде. Бик күп нәрсәләрнең асылы ачыла, төсләре уңа, шунлыктан тарту көче дә кими. Мин хәзер разведчик булырга теләмим инде. Малай чак ахмаклыкларын хәтерләп, моңсу елмаеп кына куям.

Марат КӘБИРОВ

АШАГАНГА – АШ, ЭШЛӘГӘНГӘ – ЭШ

25 июльдә Халыкара кулинарлар көне билгеләп үтелә. Шул уңайдан без дә аш-су осталары белән милли ризыкларыбыз, аларның популярлыгы турында сөйләштек. Ни өчен мондый ризыкларны заказга пешертүчеләр арткан? Яхшымы бу, начармы? Әнә шул сорауларга җавап эзләдек.

«Милли ашлар» кейтерингы (ризыклар әзерләп, өйләргә илтү, урыннарга барып, табын кору) җитәкчесе, әле күптән түгел генә 71 килолы бәлеш һәм 8 мең йомыркадан тәбә пешереп, рекорд куючыларның берсе, аш-су остасы Альбина Фәсхиева күп кенә милли ашларның онытылып баруына борчыла.

– Мин күбрәк Балтач районында эшлим. Дөресен генә әйткәндә, хәтта бәлешне дә заказ биреп пешертүләренә аптырыйм мин. Һәм сәбәбен дә аңлата алмыйм. Бер авырлыгы юк кебек үзенең. Ярымфабрикатлар – мантый, өчпочмак, бөккән ише ризыкларга да заказларыбыз күп. Шуларны өйдә пешерүчеләр кими. Яшьләр хәтта бәлешнең нәрсә икәнен дә белми. Адым саен пешкән ризык саталар, аның сыйфаты турында әйтмим дә инде. Рәхәт бит, үткәндә-сүткәндә алдың да киттең – әзер ризык. Ләкин шул рәвешле кеше чын өчпочмакның тәмен оныта бит.

Ә Казан халкының, Европа кухнясыннан туеп, үзебезнең милли ризыкларга кайтуына игътибар итә башладым. Сагынганнар. Без бит элеккедән килгән ризыкларны – куллама, карта, чумар ашы, борай бәлеше пешерергә тырышабыз. Кемдер алар турында беренче кат ишетә. Үзебезнең милли ризыклар онытылмасын, пешермәсәләр дә, яшь буын татып булса да карасын дип тырышабыз.

Ничек кенә булмасын, бәйрәм табыннарына милли ризык пешертүчеләрнең күп булуы сөендерә, билгеле. Соңгы елларда аеруча актуаль бу. Атна ахыры якынлаша башлауга, заказларыбыз кисәк арта, – дип сөйли ул.

Мамадышта яшәүче аш-су остасы Алия Мортазина әйтүенчә, киресенчә, соңгы елларда халык үзе дә хирысланган, заказлар бераз кимегән.

– Безнең районда аш-су осталары бик күп. Соңгы өч елда заказлар саны бераз гына кимеде. Хәзер бит рецептлар интернет тулы, яшьләр өйрәнә, үзләре пешерергә тырыша. Ә зуррак мәҗлесләргә – туй-никахларга бавырсак, чәкчәк пешертүчеләр бик күп. Үзебезнең ризыклардан тыш, пәхләвә, каравайны да еш сорый башладылар. Бәлешне дә еш пешерергә туры килә. Кыскасы, милли ризыкларыбыз бүген дә һәр бәйрәмнең күрке булып тора.

Өйдә дә табыннан төшми алар. Балалар кунакка кайткан саен, өстәл түренә бәлеш менеп утыра. Борай бәлешен, тары кыстыбыен яратып пешерәм. Алар онытыла башлады инде, сирәк пешерәләр. Ләкин без әле дә бик яратып ашыйбыз, – ди Алия ханым.

Аш-су остасы, блогер Эльмира Камалиева белән тәмле балачакка кайтып килдек.

– Татар милли ашлары диюгә, күңелем белән балачакка, авылга кайтып китәм. Элек дус-туганнар белән мул табын янында бик еш очраша идек бит. Зур бәлеш, өчпочмаклар, баскан токмачлы аш – һәммәсе табынның күрке булды. Билгеле, хәзер дә авылда берсеннән-берсе тәмле ризыкларыбыз белән каршы алалар, ләкин менә шундый очрашулар гына кимеде.

Хәзер бит яшьләрнең дә милли ризыкларга бик исләре китми. Дөрес туклану, диләр, өйдә бик сирәк пешерәләр. Аннан соң, пешереп сатучылары, хәтта китереп бирүчеләре булгач, мәшәкатьләнергә дә кирәкми. Гомумән, милли ашларны заказга пешерүчеләр бик популяр бүген. Адәм баласы җайлыга тиз ияләшә бит ул, ә кемнәрдер шуны кәсеп итеп, акча эшли.

Үзебезгә килгәндә, ирем дә, мин дә авыл балалары булгач, ит белән бәрәңге ашамасаң, тамак туймаган да кебек. Шуңа күрә милли ризыкларны бик еш пешерәм. Балаларыбыз да бәлеш, өчпочмак, гөбәдияне бик яратып ашый. Кулың эш белсә, тамагың тук була, диләрме әле? Мин шуңа, кесәгә дә бәрми, дип өстәр идем, – ди ул.

Мәҗлес табынына ризыкларны заказ биреп пешертүчеләр болай да күп мәшәкатьне бераз булса да киметергә тели. Аш-су остасы, заказга милли ризыклар пешерүче Лилия Сәгъдиева шулай ди.

– Милли ризыкларны заказга пешерүчеләр дә, сатып алучылар да байтак хәзер. Күбесенчә чәкчәк һәм бавырсак пешергәч, миңа туй, никах мәҗлесләренә заказ бирәләр. Моны халыкның ялкаулана баруына сылтамас идем. Андый мәҗлесләр вакытында кешенең эше тыгыз, мәшәкате болай да күп була бит. Ә туй белән никах табынын чәкчәк белән бавырсактан башка күз алдына китереп булмый. Шуңа күрә күпләр заказ бирергә ашыга. Сатып алучыларым арасында 27дән 40 яшькә кадәргеләр күбрәк.

Үзебезнең табыннан да төшми милли ризыклар. Аеруча бәлешне яратып пешерәм, һәм яратып ашыйбыз да. Пироглар белән дә еш сыйларга тырышам, – дип сөйли Лилия ханым.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

vk.com/milliashlar

Эльмира Камалиевадан баш-аяк бәлеше рецепты

Камыр өчен кирәк:
1 стакан су, 1 стакан май, 1 аш кашыгы майонез, тәменчә тоз, бераз сода, он.
Эчлек өчен кирәк:
борай (алдан бүрттереп, пешереп алырга кирәк), 3 баш суган, тәменчә тоз, тәменчә борыч, үрдәкнең муен, канат, эчке өлешләре (йомшак булсын өчен, 1,5 сәгать тирәсе аерым казанда пешереп аласы).

Камырын басабыз, җәябез дә, эчлеген салып, мич яисә духовкага озатабыз. Бәлеш пешеп чыгар алдыннан, капкачын ачып, ите кайнаган майлы шулпаны салабыз. Тәмле булсын!

МОҢЛЫ ТИМЕР

Аның кул астында тимер дә «яфрак яра, чәчәк ата». Арчада яшәүче Зөлфәт Абдуллин турында әнә шулай диләр. Нинди генә бизәкләр ясамый да, кая гына кунмый ул оста тимерче ясаган бизәкләр. Капка-коймалар, атынгычлар, гөл савытлары… Кем нәрсә сорый, тимердән шуны ясап бирә Зөлфәт.

Барысы да туган көн бүләгеннән башлана. 27 яшьлегенә эретеп ябыштыру аппараты бүләк итеп сөендерәләр аны. Аннары ул башкаларны сөендерә башлый.

– Башта үземә эшләдем, аннан күршеләргә, күршеләрнең күршеләренә. Шуннан әкренләп эш китте. Социаль челтәрләр бик юк иде әле ул вакытта. Иң яхшы реклама «сарафан радиосы» диләр бит. Минем бу эш белән шөгыльләнә башлавыма быел менә җиде ел була. Бер заказ биргән кеше ел саен нидер ясатып ала, – ди оста.

Зөлфәт Арчадагы данлыклы педагогика көллиятенең музыка бүлеген тәмамлаган, фортепиано буенча мөгаллим. Армиягә киткәнче, ике ел мәктәптә эшләргә дә өлгерә. Ә күңелдәге матурлык, рухи байлык, кем кайда нинди эштә хезмәт куйса да, аның үзе белән йөри. Зөлфәт белән дә шулай.

Моңлы күңелле тимер остасының хатыны Эмилия белән танышулары да очраклы рәвештә килеп чыккан. Егет кызга ялгышып, башка кешенең номерын бутап шалтырата. Беренче сөйләшү соңгысы булмый, яшьләр аралаша башлый. Эмилия – Башкортстан кызы. Зөлфәт белән та-

нышканда Казанда финанс-икътисад институтында белем алып йөри. Ул укуын тәмамлагач, яшьләр гаилә кора һәм Арчага кайтып урнашалар.

– Мине илһамландыручы да, әйдә, син булдырасың, курыкма, эшлибез, дип көч биреп торучы кеше дә – Эмилия, – ди Зөлфәт. Әлбәттә инде, хатынның финансист булуы да эшне көйләп, санап алып барырга ярдәм итә.

Тимергә бәя арту да, кризис та Зөлфәтләрнең эшләренә тәэсир итмәгән. Аллага шөкер, заказлар күп, өйдә торган да юк, ди.

– Бер елны кешеләр күп итеп атынгычка заказ бирсә, икенче елга капка һәм койма була. Быел менә бөтен кеше диярлек мангал ясата. Атынгычларга заказ бөтенләй юк диярлек, ә узган ел ясап өлгерә алмадык. Заказларның нәрсәгә бәйле рәвештә үзгәрүе үзебезгә дә кызык. Ләкин асылын аңламыйбыз, – дип елмая Зөлфәт.

Эш кешене түгел, кеше эшне таба, диләр бит. Зөлфәт – шуның бер мисалы. Югыйсә эретеп ябыштыручылар да, капка-койма ясаучылар да буа буарлык. Үзен дә, үзе белән эшләүче өч егетне дә эшле иткән Зөлфәт. Теләүче булса, тагын кеше алырга әзер ул. Ләкин андыйлар бик күренми икән. Менә шундый гаҗәп хәл. Берәүләр авылда эш юк дип зарланганда, икенчеләре эшләргә кеше таба алмый. Зөлфәтләргә исә тагын да күбрәк эшләргә, башкаларны сөендерергә туры килә.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 306

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+